**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.12.2016 № 743

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 25 гыйнварында теркәлде, № 3803

“Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы комиссиясе турында” 05.09.2016 № 509 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәткәрләренә карата куела торган чикләүләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәүне тәэмин итү һәм коррупцияне кисәтү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. “Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы комиссиясе турында” 05.09.2016 № 509 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать, гариза, уведомление коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең вазыйфаи затына, яисә Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә тапшырыла, һәм, кабул итеп алынган көнне, Комиссия утырышын үткәрүгә нигезләрдән торган мәгълүматларны теркәү журналында теркәүгә алынырга тиеш.

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәреннән мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алырдай шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында уведомлениене алу тәртибе “Дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алырдай шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 16.02.2016 № 77 Министрлык боерыгы нигезендә җайга салына.

Мөрәҗәгатьтә, гаризада, уведомлениедә дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, яшәү урыны адресы, били торган дәүләт хезмәте

вазыйфасы күрсәтелә.

Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне тапшырганда, шулай ук дәүләт хезмәтеннән киткәч соңгы ике ел эчендә биләгән вазыйфалары, коммерцияле яки коммерциясез оешманың атамасы, урнашу урыны, эшчәнлегенең нинди характерда булуы, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән вакытта гражданин тарафыннан башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерцияле яки коммерциясез оешмага карата дәүләт идарәсе функцияләре, килешү төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), аның гамәлдә булуының күздә тотылган срогы, килешү буенча эшләр (хезмәт күрсәтүләр) башкаруга түләү суммасы күрсәтелә.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык белән таныштырырга.

Министр Э.Ә. Зарипова